# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Зур Полянка авыл җирлеге составына керүче
Зур Полянка авылы торак пунктында

2020 елның 10 ноябре
№ 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге составына керүче Зур Полянка торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда Зур Полянка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, гражданнарның үзара салымын 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:
   - авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча хезмәт өчен түләү);
   - техниканы – тракторны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы);
   - авыл җирлегенең торак пунктында урамнарны яктырту (урам фонарьлары, исәпкә алу приборлары сатып алу, СИП үткәрү, килешү буенча хезмәт өчен түләү);
   - янгынга каршы гидрантлар урнаштыру.

3. Әлеге карарны Зур Полянка авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы М.Р. Афанасьева